ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 14 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 11 (I өлеш); 2015, № 12 (I өлеш); 2016, № 1 – 2, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 38 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш); 2022, № 57 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 20 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 5 өлешендә «ул» сүзеннән соң «әлеге Законның 5 статьясындагы $3^1$ өлешендә каралган очракта күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яисә) эшләр башкару өчен кирәкле товарлар (материаллар һәм җайланмалар, шул исәптән югары технологияле җайланмалар) өчен түләүгә, шулай ук» сүзләрен өстәргә;

2) 5 статьяда:
а) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ өлеш өстәргә:
«$3^1$. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты региональ операторга аның счетында булдырыла торган, күләме капиталь ремонт өчен кертемнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнгән минималь күләменнән чыгып формалаштырылган капиталь ремонт фонды акчалары исәбеннән финансланучы күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яисә) эшләр башкару өчен кирәкле товарлар (материаллар һәм җайланмалар, шул исәптән югары технологияле җайланмалар) сатып алу вәкаләтен, шулай ук сатып алынган һәм күпфатирлы йортта гомуми

мөлкәткә капиталь ремонт ясауда файдаланылмаган мондый товарларны (материалларны һәм җайланмаларны, шул исәптән югары технологияле җайланмаларны) реализацияләү вәкаләтен бирү турында карар кабул итәргә хокуклы.»;

б) түбәндәге эчтәлекле $3^2$ өлеш өстәргә:

«$3^2$. Әлеге статьяның $3^1$ өлешендә каралган очракта региональ оператор күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яисә) эшләр башкару өчен кирәкле товарлар (материаллар һәм җайланмалар, шул исәптән югары технологияле җайланмалар) сатып алуны, шулай ук сатып алынган һәм күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауда файдаланылмаган товарларны (материалларны һәм җайланмаларны, шул исәптән югары технологияле җайланмаларны) реализацияләүне Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашыра. Бу чакта региональ оператор функцияләренә Россия Федерациясе Торак кодексының 180 статьясындагы $1^2$ өлешендә каралган функцияләр керә.»;

в) 5 өлештә «финанслау өчен» сүзләреннән соң «, шул исәптән әлеге статьяның $3^1$ өлешендә каралган очракта күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яисә) эшләр башкару өчен кирәкле товарлар (материаллар һәм җайланмалар, шул исәптән югары технологияле җайланмалар) өчен түләүгә» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 28 сентябрь
№ 81-ТРЗ